Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлегенең Курмала авылында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елның 30 ноябере №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Курмала авылында **халык җыены карар бирә**:

1. 90% күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзәләреннән кала һәр гражданга 2024 елда узарасалымны 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

-Курмала авылында: - Бөек Ватан сугышына багышланган һәйкәлне төзекләндерү;

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга , http://pravo.tatarstan.ru. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына керту өчен җибәрергә.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин